Татарстан Республикасы Нурлат шәһәре 6 нчы номерлы «Кояшкай» балалар бакчасы мәктәпкәчә белем муниципаль бюджет учреждениесе

# “Без нәни артистлар” түгәрәгенең эш программасы

(үзләштерү вакыты1 ел, 6-7 яшьлек балалар өчен )

Программаны төзүче:
тәрбияче Мотыгуллина Алия Сабир кызы

Нурлат шәһәре.

# Эчтәлек.

1. Аңлатма язуы......................................................................3
2. Программаның максаты..........................................................3
3. Программаның төп бурычлары..............................................4
4. Программаның билгеләнеше...................................................4
5. “Без нәни артистлар” түгәрәгенең актуальлеге..........................4
6. Программаның структурасы...................................................5
7. Түгәрәкнең көтелгән нәтиҗәсе...............................................6
8. Ата-аналар белән эш..............................................................6
9. Эш формалары........................................................................6
10. “Без нәни артистлар” түгәрәгенең перспектив планы...................7-10
11. Кулланылган әдибият.............................................................11

## Аңлатма язуы.

*Театр — яктылыкка, нурга илтә,*
*Кире юлга җибәрми, уңга илтә.*
*Г.Тукай*

Бакчадагы тәрбия һәм белем бирү эшчәнлегендә бала яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән аралашырга, әйберләрне танып белергә өйрәнә. Балаларны берләштерүдә, зурлар белән аралашуга өйрәтүдә, сөйләм телен үстерүдә, җәмгыятьтә үзен- үзе тота белеп, актив һәм сәләтле кеше булып үсүендә сәхнәләштерү эшчәнлегенең әһәмияте бик зур. Баланың бөтен тормышы уен. Уенда бала тирә- юнь турында, җәмгыятьнең законнары, кешеләрнең үзара аралашу матурлыгы турында мәгълүмат алып кына калмый, ә бу дөньяда яшәргә, үзенең мөгамәләләрен төзергә өйрәнә. Ә бу баланың игътибарлы, яхшы хәтерле, дөрес, матур, әйбәт сөйләшә белүен таләп итә. Сәхнәләштерү уеннарында катнашып, балалар образлар, төсләр, авазлар аша тирә- юнь белән танышалар, ә сораулар балаларны уйларга, анализларга, йомгаклау ясарга мәҗбүр итә. Сәхнәләштерү эшчәнлеген алып барганда, һәр бала үзенең кичерешләрен, тойгыларын, теләкләрен, карашларын гадәти сөйләшкәндә генә түгел, ә чит тыңлаучылар алдында күрсәтә алырлык шартлар тудырырга һәм яшьтән үк өйрәтергә кирәк. Еш кына без киң белемле, сәнгатьле сөйләшә белүчеләрне оялчан икәнен, чит кешеләр алдында югалып калуларын күзәтәбез. Бу проблемалар булмасын өчен, балалар бакчасында театр кую бик зур булышлык күрсәтә. Сәхнәләштерелгән уеннар балаларны шатландыралар. Спектакльләрдә катнашып, балалар тирә-юнь белән, төсләр, авазлар белән танышалар, ә уйланылып куелган сораулар балаларны анализларга, уйланырга, нәтиҗәләр ясарга өйрәтә. Сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәнү барышында, сизелмичә баланың сүз байлыгы арта, бала чиста, дөрес, аңлаешлы итеп сөйләргә өйрәнә. Сүзлек формалаша- яңа сүзләр белән баетыла.

## Программаның максаты:

Театральләштерү алымнары аша балаларда театр сәнгатененә кызыксыну һәм омтылыш, зур сәхнәдә чыгыш ясап үзеңне сынап карау теләге уяту; балалар әдәбиятының иң матур үрнәкләре, халык авыз иҗатының төрле формалары белән таныштыру; әдәби телдә сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен камилләштерү, эстетик зәвыкларын, иҗади сәләтләрен, башкару осталыкларын үстерү; халкыбызның әдәбияты, сәнгате, мәдәнияте, гореф-гадәтләре үрнәгендә әхлаклы, югары культуралы шәхесләр тәрбияләү.

## Программаның төп бурычлары:

- балаларның актерлык осталыгына өйрәтү;

- акыл үсеше белән сөйләм теленең үсешен үстерү, персонажлар сөйләмен сәнгатьле итеп сөйләү өстендә эшләү, баланың сүз байлыгын арттыру, аваз культурасы, интонацияле сөйләүен тәрбияләү;

- вак моториканы үстерү;

- хәрәкәт күнекмәләрен формалаштыру;

- курчакларны хәрәкәтләндерергә өйрәтү;

- сәхнәләштерү эшчәнлегенә тотрыклы кызыксынуны үстерү ;

- мимика, ишарәләр, хәрәкәтләр, интонацияне, тәэсирле чараларны кабатлау теләге тудыру.

- балаларда эстетик, әхлак һәм хезмәт тәрбиясен тормышка ашыру;

- балаларның сәламәтлеген яхшырту;

- сәнгатькә кызыксыну һәм мәхәббәт тәрбияләү.

## Программаның билгеләнеше:

“Без нәни артистлар ” түгәрәге программасы мәктәпкәчә әзерлек төркеме өчен тәкъдим ителә.

**Тормышка ашыру вакыты:** 1 ел.

**Түгәрәкнең эшләү режимы:** атнага 1тапкыр үткәрелә, көннең икенче яртысында.

**Елына:** 36 сәг.

**Түгәрәкне үткәрү вакыты:** 30 минут.

## “Без нәни артистлар” түгәрәге программасының актуальлеге:

белем һәм тәрбия алуда универсаль гамәлләрнең берсе коммуникатив гамәлләрнең камил формалашуы. Ягъни, баланың үз фикерен диалогта һәм монолог рәвешендә башкаларга дәлилле итеп, әңгәмәдәшен кимсетмәслек итеп җиткерә белүгә әзерләү. Бу таләп – түгәрәкнең актуальлеген раслаучы мөһим дәлил дә. Балаларны берләштерүдә, зурлар белән аралашуга өйрәтүдә, сөйләм телен үстерүдә, җәмгыятьтә үзен-үзе тота белеп, актив һәм сәләтле кеше булып үсүендә сәхнәләштерү эшчәнлегенең әһәмияте бик зур.

## Программаның структурасы:

Программа 3 бүлектән тора :

1. Кереш. Театр турында гомуми белемнәр.
2. “Курчак театры”.
3. “Без театр уйныйбыз”.

Программаның беренче бүлегендә балалар театр турында яңа мәгълүмат алалар, театрда тоту күнекмәләрен яңарталар; икенче бүлектә әкиятләр иленә сәяхәт итәләр, “Әкият” курчак таетры белән танышалар, курчакларның төрләре, аларны хәрәкәтләндерергә өйрәнәләр. Өченче өлештә, үзләре костюмнар киеп тамашалар куялар.

Сәхнәләштерү эшчәнлеге

- аудиоязмалар тыңлау, курчак театры, мультфильнар, театраль тамашалар карау һәм алар буенча әңгәмә оештыру;
- уен- драматизацияләр;
- сәнгатьле итеп сөйләү күнегүләре;
- этика буенча аерым күнегүләрне үз эченә ала.

Ә менә тәрбияче үзе сәнгатьле итеп сөйләү генә түгел, күрә, ишетә белергә, актерлык, режиссерлык осталыгына да әзер булырга тиеш. Тик ул үзенең актерлык осталыгы белән оялчан баланың уйнау теләген бетереп, карауычыга әйләндерергә тиеш түгел. Балалар ялгышудан куркырга, гел карауч гына яки гел катнашучы гына булырга тиеш түгел.

Рольләргә бүлгәндә төрле алымнар кулланыла:

- баланың теләге буенча роль сайлау;
- төп рольләргә оялчан балаларны билгеләү;
- рольләрне бүлү;
- парлап, төркемләп уйнау.

Монда ике проблема килеп чыгарга мөмкин:

- һәр балага рольләр житмәсә нишләргә;
- тискәре рольләрне кем уйнар?

Беренче проблеманы балаларны төркемнәргә бүлеп чишеп була. Ә икенчесен аңлатырга: әкияттә, сәхнәдә барысы да артистлар. Ә артист уңай рольне дә, тискәре рольне дә уйный белергә тиеш. Тискәре рольне уйнау күпкә катлаулырак та, һәр бала тискәре рольне дә, уңай рольне дә уйный белергә тиеш.

## Түгәрәгенең көтелгән нәтиҗәсе:

Сәхнәләштерү уеннарын үзләштерү ярдәмендә балаларның интонацияләре яхшыра, башка катнашучылар белән аралашу осталыклары арта. Балаларның бәйләнешле сөйләм телләре үсә.

- Балалар милли культура, театр, артистлар дөньясы турында белергә тиеш.
- Сәхнәләштерү уеннарын үзләштерү ярдәмендә балаларның интонацияләре яхшыра, башка катнашучылар белән аралашу осталыклары арта. Балаларның бәйләнешле сөйләм телләре үсә.
- Сәхнә тормышында үзеңне иркен тоту күнекмәләренә төшендерү.
- Курчаклар белән иркен хәрәкәт итүгә ирешү.
- Гаилә белән балалар бакчасы арасында җылы мөнәсәбәт урнаштыру.

## Ата-аналар белән эш

1. Әти-әниләр арасында анкета үткәрү, фикерләре белән уртаклашу.
2. Төркемдәге театр почмагын яңарту.
3. Сәхнәләштерү өчен косюмнар җитештерү.
4. Консультация “Бала тормышында театр”.
5. Әңгәмә “Өйдә гаиләбез белән театр уйныйбыз”
6. Әти-әниләр өчен йомгаклау түгәрәк эше: “Уйныйбыз да, җырлыйбыз да!” (күңел ачу кичәсе, май)

## Эш формалары

- әти – әниләр өчен йомгаклау күңел ачу кичәсе;
- кечкенәләр каршында чыгыш ясау;
- халык авыз иҗаты, матур әдәбият үрнәкләре белән танышу;
- рольләргә бүлеп уйнау, сәхнәләштерү;
- тел гимнастикасы, артикуляцион күнегүләр ясау;
- әңгәмә, фикер алышулар;
- кул эше, рәсемләү;
- рәсемнәр, иллюстрацияләр, мультфильмнар карау;
- җырлы – биюле, сүзле, өстәл арты уеннары.

## «Без нәни артистлар» түгәрәгенең перспектив планы

| Ватыты | Тема | Сәг. саны | Программаның эчтәлеге |
|---|---|---|---|
| Сентябрь | Кереш. Театр турында әңгәмә. Сюжетлы-рольле уен «Без театрда» | 1 | Балаларда театр, театр сәнгате, анда эшләүчеләр турындагы күзаллауларын баету. Сәхнә серләренә өйрәнү. Рольга керә белүләренә ирешү. Кызыксынучанлылык тәрбияләү. |
| | Курчак театры турында сөйләшү. Казан “Әкият” курчак театры, курчак театры төрләре белән танышу (презентация карау) | 1 | Курчак театры турында белемнәрен киңәйтү. Театр төрләре белән танышу (бармак, перчатка, бибабо, шәүлә һ.б.) Курчакларны хәрәкәтләндерергә өйрәнү. Ширма артында тоту күнекмәләренә төшенү. Проблемалы ситуацияләр чишү. Күзаллауларын баету. |
| | “Өч кыз” әкияте (өстәл театры кую) | 1 | Әкият аша балаларда әниләргә карата игътибарлылык үстерү; ихтирам, хөрмәт хисләре тәрбияләү. |
| | Мультфильм карау. А.Алиш “Сертотмас үрдәк» . | 1 | Мультфильм карау. Балаларда серне саклый белү, иптәшләреңне авыр хәлдә калдырмау сыйфатлары тәрбияләү. Хәрәкәтләрне башкару, сәнгатьле сөйләү буенча эш. |
| Октябрь | А. Алишның “Сертотмас үрдәк” әкиятен сәхнәләштерү. | 1 | Иллюстрацияләргә нигезләнеп эчтәлекне сөйләү. Рольләрне бүлешү. Костюмнар әзерләү. Сәхнәләштерү осталыкларын үстерү. |
| | Төрекмән халык әкияте “Икмәк” белән танышу. | 1 | Икмәк турында әңгәмә үткәрү, әкиятнең эчтәлеген аңлап, сөйлиәргә омтылу. |
| | Абдулла Алишның “Куян кызы” әкиятен сәхнәләштерү. | 2 | Абдулла Алишның “Куян кызы” мультфильмын карау, эчтәлеге буенча фикер алышу, сөйләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | Декорация ясау. Музыка сайлау. Рольләрне бүлешү. Сүзләрне өйрәнү. |
| Ноябрь | Татар халык әкияте “Төлке белән бүре” | 1 | Рәсемнәргә нигезләнеп, әкиятне сөйләү, геройларын билгеләү. Төлке һәм бүре образларына характеристика бирү. |
| | А.С.Пушкин иҗаты белән танышу. “Патшаның үлгән кызы һәм җиде баһадир турында әкият” белән танышу. | 2 | А.С.Пушкин иҗатына карата кызыксыну уяту, әкиятне рәсемнәр буенча сөйләү. Ошаган образның рәсемен ясау. |
| | Рус халык әкияте “Казлар - аккошлар” белән танышу. Мультфильмын карау. | 1 | Әкиятнең эчтәлеген аңлау, үз сүзләрең белән кыскача сөйли белү. |
| | “Казлар – аккочлар” әкиятен сәхнәләштерү. | 2 | Төрле халык әкиятләренә карата кызыксыну уяту , кешелеклелек (ихтирамлылык, дуслык, хезмәт сөючәнлек) сыйфатлары тәрбияләү. |
| Декабрь | А.Ремизовның “Ипи тавышы” әкияте белән танышу. | 1 | Рәсемнәр ярдәмендә әкиятнең эчтәлеген сөйләү. |
| | К.Паустовскийның “Җылы икмәк” әкиятен карау. | 1 | Икмәк темасын дәвам итү. Әкиятнең эчтәлеген аңлау, төп геройларга характеристика бирү. |
| | В.Даль “Ел карты” (Старик-годовик) әкият-табышмак белән танышу. | 1 | Әкиятне карау, табышмакларга җавап табу, балаларның игътибар-лылыкларын үстерү. Кем ул ел карты? |
| | “Кар кызы” (халык сюжеты буенча) әкиятен уку һәм сәхнәләштерү. | 2 | Әкиятне карау, декорацияләрне әзерләү, рolләрне өйрәнеп, сәнгатьле итеп сөйләргә омтылу. |
| Гыйнвар. | Ш.Перроның “Итекле мәче” (Кот в сапогах)әкияте белән танышу. Өстәл театры кую. | 2 | Мультфильм карау, мәче образына характеристика бирү. Рәсемнәр буенча әкиятне сөйләү. Рolләрне бүлеп, өстәл театры кую. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Февраль | М. Җәлил иҗаты белән танышу, шигырьләрен уку. “Карак песи” шигырен сәхнәләштерү. | 2 | “Әтәч”, “Сәгать», шигырьләрен уку. Әңгәмә: геройларны билгеләү, характерларын ачыклау. “карак песи” әсәрен сәхнәләштерү. М. Җәлил иҗатына ихтирам хисе тәрбияләү, тыңлау, ишетү сәләтен һәм сөйләм телен үстерү. |
| | Х.-К Андерсынның “Уймак кыз” (Дюймовочка) әкияте белән танышу. Өстәл театры күрсәтү. | 2 | Аудиоәкиятне тыңлау, рәсемнәр ярдәмендә әкиятне сөйләү. Әкиятләр турында булган белемнәрне ныгыту. Балаларның бәйләнешле сөйләм телен баету һәм сәхнәләштерү осталыкларын үстерү. |
| Март | “Дөньядагы иң матур кием” (Самый красивый наряд на свете) әкияте белән танышу. | 1 | Төрле милләт әкиятләренә карата кызыксыну уяту. Әкиятнең эчтәлеген аңлап, сөйли белү. |
| | “Дөньядагы иң матур кием” әкиятен сәхнәләштерү. | 1 | Әкиятне рольләргә бүлеп, сәхнәләштеру, костюмнар сайлау, декорацияләр өлгертү. |
| Апрель | Г.Тукай әкиятләрен уку, “Бала белән күбәләк” әсәрен сәхнәләштерү. | 1 | Балаларның Г.Тукай иҗаты буенча алган белемнәрен гомумиләштерү һәм балаларда шигърият белән кызыксыну тәрбияләү. Телнең сәнгатьлелеген камилләштерү, хәтер сәләтен үстерү. Шигырьләрендәге төп фикерне аңларга, әсәрне сәхнәләштерергә өйрәтүне дәвам итү. |
| | Г.Тукайның “Кызыклы шәкерт” әсәрен сәхнәләштерү. | 1 | Балаларда бер-берсен тыңлый белү сыйфаты, татар шагыйре Г.Тукай иҗатына кызыксыну тәрбияләү. Балаларның шигырьләрне сәнгатьле сөйләм осталыкларын, логик фикерләү сәләтен үстерү. Балаларның үзләре уйлап тапкан табышмаклар аша уй-фикерләрен башкаларга җиткерә алуларына, сәнгатьле итеп таныш шигырьләрен сөйләүләренә ирешү. |

| | | |
|---|---|---|
| Г.Тукайның “Һәркем эштә” әсәрен сәхнәләштерү. | 1 | Кечкенәләр төркеме балаларына Г. Тукай әсәрләрен уйнап күрсәтү теләге уяту. Уңай һәм тискәре якларны күрә белергә өйрәтү, уңай сыйфатлар тәрбияләү. |
| К.Драгунская “Тыңлаучан-лык өчен дару” (Лекарство от послушности) әкияте белән танышу. | 1 | Әкиятне тыңлау, керпе нинди образларга керүен аңлату, балаларның керпегә екарашы. |
| “Үрдәк беренчелекне алган” әкияте белән танышу. Әкиятне сәхнәләшттерүгә омтылу. | 3 | Әкиятнең эчтәлеге белән танышу, артор сөйләменә игътибар бирү. Геройларга характеристика бирү. Кечкенәләр төркеме балаларына әкиятне тәгъдим итү. |
| Ф.Зарифның “Татлы җәй” әсәре белән танышу. | 1 | Балаларны хикәя белән таныштыру.Күзаллау сәләтләрен үстерү. Җәйге табигатьне күрә белергә өйрәтү,аңа карата мәхәббәт тәрбияләү. |
| Әти-әниләр өчен йомгаклау түгәрәк эше: Уйныйбыз да, җырлыйбыз да! (күңел ачу кичәсе) | 1 | Эшебезгә нәтиҗә ясау. Әти-әниләргә әкиятләрдән өзекләр сәхнәләштереп күрсәтү, бергәләп уеннарда катнашу. Бердәмлек, татулык хислре тәрбияләү. |

## Кулланылган әдәбият


1. Туган телдә сөйләшәбез 5-7 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәту буенча методик кулланма. Казан "Хәтер" 2016.
2. Закирова К.В., Гаффарова С.М. “Әткәт-әнкәмнең теле”. Казан “Мәгариф”, 1997.
3. Ягъфаров Р.А. “Татар балалар фольклоры” Казан “Раннур” 1999.
4. Харрасова Р.Ф. “Бармакларны уйнатыйк, туган телне өйрәник” Казан “Хәтер” 1997.
5. Балалар өчен хрестоматияләр: “Гөлбакча”, “Раушан көзге”, “Балачак аланы” Казан: РИЦ, 2011.
6. Закирова К.В. “Уйный-уйный үсәбез” Казан“Мәгариф”,2005.
7. Закирова К.В. “Әй уйныйбыз, уйныйбыз...” Казан, 2013.
8. Закирова К.В., Кадыйрова Р.Ә., Сафиуллина Г.М. “Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе” Казан, 2013.
9. Журналлар: “Мәгариф”, “Күчтәнәч”, “Салават күпере”, “Тылсымлы куллар”
10. Антипина А.Е. Театрализованная деятельность в детском саду. - М.: ТЦ Сфера, 2006.
11. Волшебный праздник/ Сост. М. Дергачева/. - М.: РОСМЭН, 2000.
12. Лебедев Ю.А. и др. Сказка как источник творчества детей /Пособие для педагогов дошкольных учреждений/. - М.: ВЛАДОС, 2001.
13. Маханева М.Д. Театрализованные занятия в детском саду. - М.: ТЦ Сфера, 2001.